# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм торак пунктында халык җыены
нәтиҗәләре турында

**№ 2** **«18» декабрь 2021 ел**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2021 елның 18 декаборендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Әбсәләм торак пунктындагы Совет урамына асфальт салу (сатып алу, алып кайту, түшәү, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Әбсәләм торак пунктындагы Юл буе урамында су линиясе төзү (материаллар, җиһазлар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Әбсәләм торак пунктында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлаштыру (трактор өчен ягулык, запас частьлар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 572 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 296 кеше катнашты, бу барлык исемлектәге халыкның 51,7 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 295 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип исәпләргә.

2. "2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Әбсәләм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешегә 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Әбсәләм торак пунктындагы Совет урамына асфальт салу (сатып алу, алып кайту, түшәү, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Әбсәләм торак пунктындагы Юл буе урамында су линиясе төзү (материаллар, җиһазлар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Әбсәләм торак пунктында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлаштыру (трактор өчен ягулык, запас частьлар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб - адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева